**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 13 » 07 2018 ел № 141

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының «Азнакай муниципаль районы торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуның генераль схемасы турында» 2012 елның 20 ноябрендәге 278 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 31 декабрендәге 503-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар итәм:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының «Азнакай муниципаль районы торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуның генераль схемасы турында» 2012 елның 20 ноябрендәге 278 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 бүлекнең 36,37 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«калдыкларны җыю - калдыкларны алга таба эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, аларны эшкәртүне, утильләштерүне, урнаштыруны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан аларны кабул итү;

калдыкларны туплау - калдыкларны алга таба эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру максатларында аларны унбер айдан да артык булмаган срокка туплау;».

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары Р.Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов